# Казаннын тарихи урыннар

# Казан Кремле

Казан Кремле – уникаль архитектур комплексы, бүгенге көндә төрле цивилизацияләр һәм мәдәниятлар арасындагы нәтиҗәле мөнәсәбәтләрне чагылдыручы объект.

Казан Кремле – Татарстан һәм Россиянең төп туризм объектларының берсе генә түгел, 2000 елда ЮНЕСКОның Бөтендөнья мирасы исемлегенә кертелү Казан Кремлен барлык дөнья халкы байлыгына әверелдерде.



# Сөембикә манарасы

Сөембикә манарасы — Казан Кирмәне җирлегендә урнашкан манара. Элек татарларда Хан мәчете буларак аталган, ләкин соңарак русларда йөргән Башня Сююмбике исеме белән атала башлый.



Сөембикә манарасы — Казанның танылган архитектура символы. Ул авышлы биналар санына керә, чөнки ул төньяк-көнчыгыш ягына 1,98 метрга ава. Якынча 1730 елларда манарага икебашлы бөркет урнаштырылды. 1980 елларда татар җәмагатьчелеге таләбе буенча манарада Ислам символы — ярым ай урнаштырылды.
Үзенең хәзерге вариантында манара 1690 еллардан соң төзелгән диеп санала. Ләкин, башка версияләргә күрә, манара Казан ханлыгы чорында төзелгән һәм шушы вакыттан калган бердәнбер тарихи бина.

# Кол Шәриф мәчете

Борынгы Кремльнең бер бизәге – зәңгәр гөмбәзле ап-ак мәчет. Ышануы да кыен, бу бинага әле 20 яшь тә юк, гәрчә, тарихи яктан карасаң, Казан Кремлендә бу мәчет 1552 елны Казанны алганчыга кадәр ук булган.

Кол Шәриф мәчете - Казан һәм аның халкы өчен уникаль корылма. Мәчет рус һәм татар халкының бердәмлеге һәм борынгы традицияләрне торгызуның гүзәл үрнәге булды



Мәчет шәһәр һәм республика халкына Казанның меңьеллыгына лаеклы бүләк булды һәм хәзер ул Благовещение соборының күршесе булып тора

# Г. Камал театры

**Театр – милләт язмышының һич тутыкмас көзгесе ул. Г. Камал исемендәге Татар дәүләт академия театры да күп еллар буе шул дәрәҗәдә бурычын уңышлы үти. Аның Мәскәүдә дә, Петербургта да, чит илләрдә дә абруе хаклы рәвештә арта бара.**



# Габдулла Тукай музее

**Музей 1986нчы елда ачылып, хәзерге көнгә кадәр уңышлы эшләп килә. Анда шагыйрь белән турыдан-туры бәйләнгән, Тукай яшәешенә һәм көнкүрешенә нисбәтле биш экспонат бар. Алар музейның чын мәгънәсендә горурлыгы булып торалар.**

